**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| _22.06.2021___ | | __695-р__ |

**Әлмәт район нефть үткәрү идарәсе
(«Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы)
«Орленок» ял базасының 1 нче, 2 нче су
җыю скважиналарын санитар саклау
зонасының беренче поясын билгеләү
турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы нигезендә, 2017 елның 5 июнендәге Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ АЛМ 01757 ВЭ лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Әлмәт, Зәй, Лениногорск районнарындагы территориаль бүлегенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2016 елның 11 гыйнварындагы № 16.07.01.000.Т.000001.01.16 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «Транснефть-Прикамье» АҖ тарафыннан тапшырылган «Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында су алу скважиналарының санитар саклык зонасы проекты нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. 1 нче кушымта нигезендә «Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында 1 нче, 2 нче су алу скважиналарының санитар саклык зоналарындагы 1 нче пояс чикләрен билгеләргә.

2. 2 нче кушымта нигезендә «Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында 1 нче, 2 нче су алу скважиналарының санитар саклык зоналарындагы 1 нче пояс чикләрендә территориядән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Транснефть-Прикамье» АҖ;
- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалы, – санитар саклык зонасын билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

- Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Орленок» ял базасында су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләре, су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру;
- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 22
июнендәге 695-п номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

**«Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында 1 нче, 2 нче су алу скважиналарының санитар саклык зоналарындагы беренче пояс чикләре**

«Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында ике скважинадан (берсе – эшли торган, берсе – резервта тора) торган җир астыннан су алу корылмасы ял базасы территориясенең көньяк өлешендә, Әлмәт шәһәреннән 10 км төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Скважиналар арасындагы аралык – 5 м.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

1 нче скважина: төньяк киңлектә – $54^0$58′23,4′′, көнчыгыш озынлыкта – $52^0$26′11,5′′;

2 нче скважина: төньяк киңлектә – $54^0$58′23,4′′, көнчыгыш озынлыкта – $52^0$26′11,8′′.

Санитар саклык зонасындагы беренче пояс астында урнашкан кишәрлекнең кадастр номеры: 16:07:010003.

Беренче поястагы санитар саклык зоналары (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала.

Сулы горизонтның яхшы якланган булуын исәпкә алып, су алу скважиналарында санитар саклык зонасының беренче поясы радиусы скважиналар авызыннан 30 метрга тигез. «Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы беренче поясның берләштерелгән чиге 60х65 м үлчәмендәге овал рәвешендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның «22»
июнендәге 695-п номерлы
боерыгына 2 нче кушымта

**«Транснефть-Прикамье» АҖ Әлмәт Район нефть үткәрү идарәсенең «Орленок» ял базасында 1 нче, 2 нче су алу скважиналарының санитар саклык зоналарындагы беренче пояс чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.